# Шагыйрь, педагог Равил Сәйфетдиновның тормыш юлы һәм иҗатын өйрәнү буенча сыйныфтан тыш чара сценарие

15 нче мәктәп укытучысы Гатауллина Резеда Гайсовна

**Алып баручы.**

Табигатьнең иң гүзәл почмаларыннан берсе - Яшел Үзән районының Мулла иле авылы. Бу авыл матурлыгы белән генә түгел тырыш гади кешеләре белән дә данлыклы. Мулла Иллендә татарның бөек шәхесләре Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри, Һади Такташның якты эзләре саклана. Мулла Иле Баһаветдин Вәисов, Гайнан Вәисов кебек бөек фәлсәфәчеләрнең, күренекле галим Гомәр Саттаровның, тарихчы галим Хәйретдин Гыймадиның туган авылы да. Ономастика өлкәсендә зур белгеч булган Гомәр ага кече ватанының тарихын кат-кат өйрәнгән. Һәм «Чал тарихлы авылым» исемле хезмәт язган. Галим: «Мулла Иле авылына Болгардан килгән кешеләр нигез салган. Алар монда, монгол яулары Болгар шәһәрен тар-мар иткәннән соң, 1240 елда качып-күчеп килгәннәр», – дип яза.

Ә бүгенге көндә авыл тарихы өйрәнелеп беткәнме соң? Моның белән шөгыльләнүче бармы соң? Тирән саф сулы чишмәләр саекмаган кебек, Мулла Илендә дә талантлы кешеләр туып тора. Шуларның берсе, авылның тарихын өйрәнүне дәвам итеп яңа китап язып бастырган, тормышның ачысын-төчесен татыган, якташларының зур ихтирамын казанган шәхес – Равил Сәйфетдинов.

**1 нче укучы.**

Равил Сәйфетдинов хакында сөйләгәндә, әлбәттә, аның иң беренче чиратта аның гади бер авыл кешесе булуын әйтергә кирәк. Тик аның бу гадилеге артында зыялыгы, кешелеклелеге яшеренгән. Тормыш авырлыкларына бирешмичә, Равил абый гел алга барган, акрынлап алдына куйган максатларына ирешеп барган. Бүгенге көндә арабызда булмаса да, аның туры сүзен, кирәкле киңәшләрен, канатлы сүзләргә әйләнгән гыйбәрәләрен авылдашлары, гомумән, аны белгән, хәтта, бары әсәрләре белән таныш булган кешеләр һәр көнне искә алып сөйли икән, димәк,аның гомере җирдә заяга узмаган, ул үзеннән соң якты эз калдырган. Бу эз- Мулла иле халкы өчен,гомумән, бөтен татар халкы өчен тырыш хезмәт, кешелеклелек, иманлы гадел тормыш үрнәге булып тора.

**2 нче укучы.**

Сәйфетдинов Равил Гарәфетдин улы 1938 нче елның 14 нче октябрендә Яшел Үзән районының Мулла Иле авылында туган. Урта мәктәпне бетергәч, 1965-196 1нче елларда Казан дәүләт унивеситетында укыган. 1961-1963 нче елларда Самара өлкәсендәге Гали урта мәктәбендә укытучы булып эшләгән. 1963-2007 нче елларда берөзлексез Мулла Иле мәктәбендә хезмәт иткән: авыл мөгаллиме буларак, татар теле һәм әдәбияты, рус теле һәм әдәбияты, немец теле, гарәп теле, дин тарихы фәннәрен укыткан. 1968-1970 нче елларда – завуч, 1971-2000 нче

елларда мәктәп директоры булган. Ул – Россиянең мәгариф отличнигы, Татарстанның атказанган укытучысы, СССР мәгариф министрлыгының Мактау Грамотасы белән бүләкләнгән. Республика матбугатында педагогик хезмәтләре, әдәби әсәрләре әледән-әле басылып тора. Равил хәзрәт Сәйфетдин 2005 нче елдан алып Мулла Иле мәчете имам-хатыйбы вазифаларын башкарды. 2017 нче елда рухи-әхлакый традицияләрне үстерүдә, тынычлык һәм конфессияара килешүне ныгытуда зур көч куйганы өчен Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хаты белән бүләкләнде.

**3 нче укучы.**

Мулла иле авылы - иман нуры балкып торган авыл, азан моңнары яңгырап торган мәчетләр авыл халкын изге эшләргә рухландыра. Монда да Равил абый Сәйфетдиновның якты эзләре саклана. Аксакал авыл мәчетендә имам вазыйфасын башкара. Гаиләгә зур шатлык килгәндә дә, кайгылы вакытта гел халык белән була ул. “Шаян сүзе белән көлдерә, төпле юанычлы сүзләре белән сабыр канатлары куя белә торган иде. Ул мине кулымнан тотып диярлек дингә алып килде, ислам нигезләрен аңлатты, намазга да аның фатихасы буенча килдем,”- дип искә ала аның хакында авылдашы Рәшит абый.

**4 нче укучы.**

**“Пәйгамбәрдән килгән сәхабәләр” әсәреннән өзек.**

Мулла Илем! Мәчетең бит һаман
Шул Муллагол корган нигездә!
Тәү мәчетне монда ул корган бит,
Имам булган – иман тергезгән.

Мин – бүгенге имам – бик үз
итепКалебемдә йөртәм гел аны.
Мин аңарга лаек булса идем –
Аллаһ йорты – ошбу бинаны

Ул күрергә теләгәндәй итеп
Исән-имин саклый алсамчы!
Муллаголның изге васыятьләрен
Киләчәккә алып барсамчы!

Мин мөнбәрдә аны күрәм төсле,
Ишетәм күк аның вәгазен –
Динне, телне мәңге үзгәртмичә
Нык сакларга чакыру авазын.

**Җыр башкарыла. “Мулилем”**

(композитор Риф Гатауллин музыкасы)

Агымсулар арасында
Иң матуры – Зөядер,
Бездә ярлар үз парларын
Гомерлеккә сөядер.

***Кушымта:***
Авылым, Мулилем,
Үстерәсең мул иген.
Мул игеннәр үскән җирем,
Гомерлегем бул минем.

Зөя суы ышанычлы –
Алып чыга Иделгә.
Мәхәббәтнең олы юлы
Илтсен безне гел бергә.

Зөя тавы артларында
Төн якты Казан барга.
Нәрсә җитә дөньяларда
Яратып сөйгән ярга.

Томаннарга төренеп пешә
Шомыртым, баланнарым.
Синңа булсын, туган җирем,
Дәртләрем, дәрманнарым.

Үзәннәрем, үрләрем лә,
Яратып туялмадым.
Гел алдагы заманнарга
Йөгерә хыялларым.

**5 нче укучы.**

Якташыбыз Равил абый Сәйфетдинов туган авылының тарихын өйрәнеп кенә калмаган, ул тарихны китап итеп тә бастырып чыгаручы кеше. "Мулла Иле турындагы китап бик күп авылдашларның теләк-тәкъдиме буенча эшләнде. Матди ярдәмне Равхат Хәмидуллин күрсәтте, бик зур рәхмәт аңа, - дип искә ала Равил абый. Туган авылын, туган ягын ярату, бөртекләп диярлек җыелган мәгълүматны киләчәк буынга җиткерү теләге бик зур була анда.

**6 нчы укучы.**

*Хәзер сезнең игътибарыгызга күрше Норлат авылы халкының яраткан чишмәләренең берсе булган "Изге Касыйм бабай чишмәсе" кыскача тарихы белән таныштырып китәм.*

Күренекле дин һәм җәмәгать эшлеклесе, шагыйрь Ибраһим улы Касыйм әл-Казани (1520- 1590 еллар арасында яшәгән) Норлат авылында туып үскән. Казан ханнарының ререзеденциясе Норлатта да булган. Зирәк һәм гаярь Касыйм ханнарның якын кешеләре белән аралашкан һәм бик җаваплы урыннарда эшләгән. 1551 нче елда Казан хөкүмәте Касыйм мулланы Мәскәүгә, сөйләшүләр алып бару өчен, илче итеп җибәрә. Мәскәү белән Казан арасындагы мөнәсәбәтләрне тыныч юл белән хәл итү өчен, Касыйм шәех зур көч куя. Мәскәү Казанга яу белән килгәч, кулына корал тотып, батырларча сугыша. Казан алынгач, татарларга яшәү өчен мөмкинлекләр оештыра. Халыкның сөекле җитәкчесенә әйләнә. Туктаусыз табиблык белән шөгыльләнә. Үзенең васыяте буенча, үлгәч, аны туган авылы Норлат төбәгендә – тау аралыгындагы аулак бер җирдә – гөбердәп чишмә бәреп торган урында җирлиләр. Бу урын изге җир булып санала. 450 ел буе бу урынга халык сукмагы өзелми.

**7 нче укучы.**

**Равил Сәйфетдинов**

**Изге Касыйм бабай чишмәсе**

Норлат, Норлат... Аның чал тарихы
Риваятьләр белән уралган.
Казан ханнары да, монда килеп,
Чишмәсеннән сихәт, көч алган.

Норлат, Норлат... Касыйм атлы улы
Ханнар йөрәгенә юл тапкан.
Мәскәү белән сөйләшергә Казан
Илче итеп аны озаткан.

Мәскәүдән яу килгәч, Касыйм мулла,
Корал тотып, батыр сугышкан,
Бер могҗиза белән исән калып,
Халык дәваларга тырышкан.

Дәвалаган күпме җанны, тәнне
Дога белән, дару белән дә,
Һәм уятып өмет киләчәккә,
Яшәү бүләк иткән меңнәргә.

Норлат, Норлат... Тауларың бик серле,
Чокырларың серле, кадерле.
Иң серлесе – изге Касыйм улы
Соң урынын тапкан каберлек.

Таулар арсында – аулак җирдә
Соң урыны Касыйм бабаның.

Бөтен яктан халык монда килә
Өмет итеп соңгы дәваны.

Бу чишмәгә иң беренче тапкыр
Килгәнемне мәңге онытмам:
Әти яуда һәлак булган дигән
Хәбәр килгән көнне фронттан.

Мин, әбигә ияреп, монда килгән идем,
Әбиемнең ачы күз яшен
Елый-елый юды һәм юатты
Изге Касыйм баба чишмәсе.

Бу чишмәгә мин кышын да киләм
Бар җир туңып, катып торса да,
Нәкъ җәйдәге кебек гөберди ул,
Бар дөньяга җылы пар чыга.

Тау куйныннан чишмә ургып тора
–Изге Касыйм баба чишмәсе.
Бу чишмәнең сихәтләре серен
Чишәсе дә әле, чишәсе.

**8 нче укучы.**

--Әйе, чишәсе дә әле чишәсе...Тик чишмә сихәтләре серен генә түгел, ә Равил абыйның саекмас иҗат чишмәсенең серләрен чишәсе иде. Чыннан да ул авыл тарихы белән кызыксынып кына калмыйча, күңелендә туган уй-кичерешләрен кәгазьгә төшерә башлый. “Кышкы каникулда” дип аталган беренче шигыре 1952 нче елның 10 нчы гыйнварында “Яшь сталинчы” газетасында басылып чыга. Бу шигырьләр, энҗе бөртекләре кебек тезелеп, матур җыентыклар хасил итәләр. Равил абыйның шигырьләр, мәкаләләр, поэма, хикәяләр тупланган дүрт җыентыгы бар. **“Китаплар исемнәре**” дип аталган нәни шигырендә бу китапларның исемнәрен укырга мөмкин:

“Кичке шәфәкъ” “Бәхет үзәне”нә
Сирпегәндә соңгы нурларын,
“Яшьлек яши безнең йөрәктә” дип
Көйлим “Мулла Иле моңнары”н.

**9 нчы укучы.**

Равил абый Сәйфетдиновның иҗат юлына басуына нәрсә йогынты ясаган соң? Бу сорауга төгәл җавап бирү кыен, тик шулай да гүзәл авыл табигатендә, тормышның авырлыкларын җиңеп үсүе, тормыш юлын да дөрес сайлый белүе сәбәбендәдер, мөгаен.
Тормыш юлы аны Казан дәүләт университетының татар филологиясе факультетына алып килә. 1959 нчы елда, зур сайлап алуны үтеп, ул шушы уку йортына укырга керә. Җәй айларында Казахстанда чирәм җирләрдә эшли. 1958 нче елда аның

“Далада туган хисләр” дигән шигырьләр циклы басылып чыга һәм аны “Чирәм җирләрне үзләштергән өчен” медале белән бүләкләнә.

**10 нчы укучы.**

Казан дәүләт университетын тәмамлагач Равил Сәйфетдиновны укытучы итеп Самара өлкәсендәге Гали авылы урта мәктәбенә җибәрәләр. Авыл халкы аны бик тә яратып өлгерә, чөнки ул университетта, гарәп телен һәм графикасын бик яхшы үзләштергәнгә, Коръәнне, аңлап, тәҗвид белән укый белә. Ул, бу авыл мәктәбендә ике ел укыта.

Нәкъ менә Гали авылында Равил абый укучылар йөрәгенә юл табарга өйрәнә. Һәр дәрескә иҗат итү ялкыны белән керә, үзенең максатына ирешә, шуннан үзенә биниһая шатлык, ләззәт алып, яңа дәресләргә канатланып керә.

1963нче елдан башлап Равил абыйның гомере Мулла Илендә уза. 1968 нче елда аны директор урынбасары итеп куялар, ә 1971 нче елның беренче гыйнварыннан 2000 нче елның беренче сентябренә кадәр ул директор була. “Мәктәп җитәкчесе булса да, әти гомергә укытучы булып калды. Үзенең һәрбер дәресенә, зур багаж, керсез иман белән кереп, иң катлаулы темаларны да укучылар рәхәтләндереп үзләштерә торган итеп оештырды, - дип яза аның хакында улы Рөстәм .

**11 нче укучы.**

Равил Сәйфетдинов - Мулла Иле халкы өчен зур ярдәмче, авыл тарихында, кешеләр күңелендә матур эзләр калдырды. Авылга кайтканның беренче көннәреннән алып бар тырышлыгын балаларга белем бирүгә бирде. Агач мәктәпне сүттереп, яңа таш мәктәп бинасын төзүтүгә күп көч куйды ул. Җәмәгать эшләрендә кайнап яшәде. Район Советы депутаты буларак, авылларга асфальт юл салдыруга үзеннән зур өлеш кертте. Агитаторлар коллективы җитәкчесе, пропагандист, авыл Советы рәисе урынбасары, Иптәшләр суды рәисе, комсомол секретаре, “Белем җәмгыяте” лекторы булды. Кичке мәктәптә яшьләрне укыту-тәрбияләүгә күпме елларын багышлады Равил абый Сәйфетдинов.

**Җыр башкарыла. “Яшел Үзән” гимны**

Урамнарың алып бара якты таңга
Алда Казан нурлар сибә киң Ватанга.
Уңда сине, данга күмеп, Идел ага,
Сулда сиңа моңнар тулы урман бага.

Идел җиле, урман шавы, рәхәт һава,
Ил күгеннән йортларыңа бәхет ява.
Бу бәхетне яуладың син зур хезмәттә,
Лаеклы син, Яшел Үзән, чын хөрмәткә.

Азмы койды батыр халкың ил калканын,
Яшәү өчен тынычлыкта гел шатланып.
Даның гизә һавларда аккошлардай
Йөрәкләрен үзең куйган очкычларда.

Корабларың урап кайта океаннардан – Дөнья
сине таный бүген әллә кайдан. Татарстан
матурлыгын гел арттырып,
Бөтен җиргә маяк булып тор яктырып.

Күтәрел син дастан булып, яшел кала,
Һәр милләткә яшел юллар сала-сала.
Горур Тукай басып торсын мәйданыңда,
Яңгырасын Сәйдәш җыры Һәрьягыңда.

***Кушымта:***
Елдан-ел яшәреп, яшә, Яшел Үзән,
Картларың, яшьләрең булсын мәңге гүзәл.
Кояшка үрелеп, елмай, шәһәр, елмай,
Иделләр гомерен бирсен сиңа Ходай.
Хөр бул син гомергә, мәңге хөрлек ярат,
Соклансын йолдызлар күктән сиңа карап.

**12 нче укучы.**

Матур гаилә дә төзеде Равил абый. Иптәше дә мөгаллимә, бергәләп алар ике ул һәм бер кыз үстерделәр. Уллары Рөстәм, бер дә шикләнмичә, нык адымнар белән этисе юлын сайлады. Хәзер Яшел Үзән шәһәренең 16 нчы мәктәбендә директор вазифасын башкара. Ул да хезмәттәшләоенең, эти-әниләрнең хөрмәтен яулаган ышанычлы шәхес.

**Алып баручы.**
Чарабызны Равил абый Сәйфетдиновның “Бәрәкәтле гомер сөрдем” дигән шигыре белән тәмамлыйсы килә.

**Бәрәкәтле гомер сөрдем**
Бәрәкәтле гомер сөрдем,
Зөя суларында йөздем,
Әрә тугайларын гиздем,
Тауларына менеп йөрдем,
Бәрәкәтле гомер сөрдем.

Зөя суларында йөздем,
Җәйләремнең мең рәхәтен,
Мең диңгезнең мең сихәтен
Аның кочагында сиздем,

Зөя суларында йөздем.

Әрә тугайларын гиздем,
Ал таңнарда хозурланып,
Чәчәкләрнең матурларын
Шигырь юлларыма тездем,
Әрә тугайларын гиздем.

Тауларына менеп йөрдем,
Күтәрелде күңел күгем,
Офыкларга бакты күзем,
Ерак-еракларны күрдем,
Тауларына менеп йөрдем.

Бәрәкәтле гомер сөрдем,
Нәрсә чәчсәм, шуны урдым,
Уңышлардан риза булдым,
Рәхмәт, җирем, барсын бирдең,
Бәрәкәтле гомер сөрдем.

Һәркайсыбызга Равил абый кебек бәрәкәтле гомер сөрергә язсын!
Игътибарыгыз өчен зур рәхмәт!